

# ЧИШМӘ БАШЫ

№7 2026ел
март

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча 8нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

*Ата –аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы*

- ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫ
- ЯҢАЛЫКЛАР
- 8 МАРТ-ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ
- 2 МАРТ - БӨТЕНДӨНЬЯ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ КӨНЕ
- Нәүрүз килә!
- МӘКТӘПТӘ ФУТБОЛ

## *Март аенда.*

*Кар дип җиргә басасың,*
*Суга кереп батасың.*
*Чыксын инде умырзая*
*Кар астында ятмасын.*

*Мартлар җитсә, яз җитә,*
*Бураннары булса да,*
*Песи чыккан урамга*
*Аяклары туңса да.*

*Ә.Бикчәнтәева*

## ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫ

- Яз көне эретмичә озак туңдырып торса, җәй коры була.
- Яз көне агачлар бөреләрен астан яра башласа, яз тиз килә.
- Кара карга килгәч, бер айдан кар китәр.
- Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр.
- Елгалар язын боздан тиз әрчелсә, ашлык уңар.
- Су ташуы куәтле булса, ашлык яхшы булыр.
- Язын иртә күк күкрәсә, ел яңгырлы булыр.
- Аккош яз көне иртә күренсә, салкын булыр, кар тиз китмәс.
- Язын сыерчык иртә килсә, көннәр җылы булыр.
- Яз көне елгаларда су артмаса,ашлык уңмас.



# ЯҢАЛЫКЛАР



Безнең тәрбиячебез Гыйлметдинова Нәзирә Зөфәр кызы "Бердәм Россия" Бөтенроссия сәяси партиясенең Арча җирле бүлегенең иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнашканы һәм Партиянең абруен күтәрүгә шәхси өлеш керткәне өчен "Бердәм Россия" Бөтенроссия сәяси партиясенең Арча җирле бүлеге Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.




16 март көнне Россия белән Кырымны берләштерү көнендә, безнең балалар бакчасы хезмәткәрләре Россия халыклары бердәмлеге елы кысаларында, Милләтләр эшләре буенча Федераль агентлык ярдәме белән "Россия – гаиләләр гаиләсе" Бөтенроссия мәгърифәтчелек акциясендә катнаштылар. Бу акцияне "Россия халыклары йорты" ФДБУ оештырды.



Безнең балалар бакчасында тәрбияләнүче Фәйзиева Зарина «Арча йолдызлары-2026» эстрада сәнгате район яшьләр конкурс-фестиваленең «Вокал-соло»номинациясендә II дәрәҗә лауреаты булды.



Андреева Виктория һәм Фәрхуллин Булат мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында "Умники и умницы" район интеллектуаль конкурсында катнашып, 3 нче урынны алдылар.



# 8 МАРТ-ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

Яз кояшы елмаеп карап, табигатьнең уяна башлаган мәлендә язның тәүге бәйрәме - Халыкара хатын-кызлар көнен бәйрәм итәбез. Хатын-кыз - ул кешегә тормыш бүләк итүче, җир йөзендәге буыннар чылбырын дәвам итүче, гомумкешелек кыйммәтләрен саклап, буыннан-буынга тапшыручы изге зат. Әниләребезнең бер җылы сүзе безнең күңелләребезне күтәрә, бер җылы карашы барлык авырлыкларны юып алгандай юкка чыгара. Хатын-кызлар - гаилә учагын сүндерми саклап тотучылар.
Безнең балалар бакчасында да кечкенә артистлар онытылмаслык программа әзерләделәр, анда һәр номер ихлас хисләр һәм балаларча самимилек белән тулы иде. Йөрәккә үтеп керә торган шигырьләр, дәртле җырлар һәм күңелле биюләр яңгырады, ә һәр чыгышта яраткан әниләргә карата аерым җылылык һәм кайгыртучанлык сизелеп торды.
Бәйрәмнең кульминациясе гаҗәеп тамаша булды, анда балалар үз талантларын гына күрсәтеп калмадылар, ә якыннарына аерым мәхәббәт белән ясалган кул эшләре бүләк иттеләр. Ә әниләрнең балалар белән бергә биюе бу күңелле чараның якты финалы булды.
Мондый бәйрәмнәр йөрәкләрне шатландырып кына калмый, ә балаларда мөһим сыйфатларны: өлкәннәргә хөрмәт, үз хисләрен белдерә белү һәм якын кешеләрне кадерләү кебек сыйфатларны тәрбияли.















# 2 МАРТ - БӨТЕНДӨНЬЯ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ КӨНЕ

2 март көнне Бөтендөнья гражданнар оборонасы көнен бәйрәм итүгә багышланган Бөтенроссия ачык иминлек мәдәнияте дәресе кысаларында, зурлар төркемендә тәрбияләнүчеләр төрле куркыныч хәлләрдә балаларның имин тәртибе буенча белемнәрен ныгыттылар, "Медицина ярдәме" сюжетлы-рольле уены барышында алган белемнәрен куллана алдылар, "Терроризм нәрсә ул?", "Янгын сүндерүче – батыр һөнәр" темалары буенча сорауларга җаваплар алдылар. Үткәрелгән чара нәтиҗәләре буенча балалар янгын вакытында һәм башка гадәттән тыш хәлләрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, өйдә һәм урамда үз-үзеңне тоту турындагы белемнәрен ныгыттылар, алган белемнәрен уеннарда, инсценировкаларда, көндәлек тормышта кулланырга өйрәнделәр.
















# Нәүрүз килә!

*Ач ишегең, керәбез,*
*Нәүрүз әйтә киләбез,*
*Хәер-дога кылабыз,*
*Аш-сый көтеп торабыз,*
*Нәүрүз мөбарәкбад!*

Нәүрүз – төрки һәм фарсы телле халыкларның бик борынгыдан килгән бәйрәме. Ул 21 мартта көн белән төн тигезләшкән көнгә туры килә.

Нәүрүз – язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме ул. Нәүрүз бәйрәме атна-ун көн дәвам иткән. Фарсыча “Нәү”-яңа, “рүз”-көн дигәнне аңлата. Көнчыгыш календаре буенча бу-Яңа елны каршылау бәйрәме. Нәүрүз бәйрәме – ул игелек, дуслык бәйрәме. Бу гүзәл, язгы бәйрәм көнендә кешеләр бер-берсенә кунакка йөриләр, бер-берсенә булган үпкәләрен оныталар, җырлыйлар , бииләр, рәхәтләнеп күңел ачалар. Бу бәйрәмнең хуҗасы- Нәүрүзбикә. Балалар йорттан - йортка кереп, “нәүрүз әйтеп” йөргәннәр.
Безнең балалар бакчасында Нәүрүз бәйрәме гөрләп узды. Нәүрүзбикә һәр төркемгә кереп балаларны бәйрәм белән котлады. Ул балалар белән бергә җырлады, биеде һәм төрле милли уеннар уйнады. Нәүрүзбикә балаларны коймаклар белән сыйлады. Шулай ук кунакка Убырлы карчык һәм Кыш бабай килде. Балалар җырлар җырладылар, биеделәр, яз һәм Нәүрүз турында шигырьләр сөйләделәр. Убырлы карчык һәм Нәүрүзбикә балаларга төрле кызыклы уеннарын уйнаттылар. Башыннан ахырына кадәр бәйрәм кәефе хөкем сөрде, балалар үзләренең артистлык сәләтләрен күрсәттеләр. Мондый фольклор бәйрәмнәре халыклар арасында дуслыкны сакларга ярдәм итә, йола бәйрәмнәренә, туган телгә мәхәббәт һәм кызыксыну тәрбияли.










# МӘКТӘПТӘ ФУТБОЛ

Бөтенроссия "Мәктәптә футбол" фестивале кысаларында әзерлек төркеме балалары футбол тренеры Насибуллин Ренат Рәшшат улы белән очраштылар. Ренат Рәшшат улы яшь футболчыларга футбол тарихы, спортчы булу өчен нинди сыйфатларга ия булырга кирәк, туклану системасы, сәламәт яшәү рәвеше турында сөйләде, шулай ук футбол кагыйдәләре белән таныштырды. Балалар треннерны зур кызыксыну белән тыңладылар, аңа сораулар бирделәр.

Аннары Ренат Рәшшат улы "мастер-класс" үткәрде, мускулларны ныгыту өчен махсус күнегүләр күрсәтте. Балалар барлык хәрәкәтләрне тырышып кабатладылар, барлык күнегүләрне дөрес башкарырга тырыштылар. Һәркем туп белән катлаулы күнегүләр башкарып, чын футболчы итеп хис итә алды.

Балалар бу очрашуга бик шатландылар һәм треннер белән хушлашырга теләмәделәр, ул аларга бу мавыктыргыч уен белән танышуны дәвам итәр өчен тагын бер тапкыр очрашырга вәгъдә итте.












*Баш мөхәррир -- татар теленә өйрәтү буенча тәрбияче: Кәримова Гүзәл Рафаил кызы*
*Мөхәррир урынбасары - логопед Шәрипова Алсинә Хаҗиәхмәт кызы*